# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 131-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Әгерҗе районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Әгерҗе муниципаль районының Әгерҗе шәһәре һәм Иж-Бубый авыл җирлеге.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Әгерҗе муниципаль районының Азево, Бима, Девәтернә, Исәнбай, Кадрәк, Кадыбаш, Кичкетаң, Красный Бор, Кырынды, Кодаш, Күләгәш, Кәчек, Яңа Бәзәкә, Салагыш, Сарсак-Умга, Иске Эсләк, Иске Чекалда, Тәбәрле, Тирсә һәм Шаршады авыл җирлекләре.